**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**№ 138** **18 сентябрь 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67 -ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында " Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Ивашкинского авыл җирлеге Уставы белән, “Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында" Ивашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 18 сентябрендәге 12 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Әлеге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: «2020 елда Ивашкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлар, 90 һәм аннан өлкәнрәк яштәге гражданнардан тыш гражданнардан үзара салым кертү белән алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме”:

-Ивашкино, Әккәрәй авылларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, юлларны грейдлаштыру, урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү) чыгымнар, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү)өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәяүлеләр күперен ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү ) өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, экспертиза һәм су анализы өчен түләү;

Әккәрәй урта гомуми белем бирү мәктәбе өчен 50 метр күләмендә койма сатып алу;

- Ивашкино урта гомуми белем бирү мәктәбенең подъезд юлын ремонтлау өчен 30 метрлы төзелеш материаллары сатып алу;

« ӘЙЕ» «ЮК»

2.Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Башлык, Ивашкино авыл җирлеге
Советы рәисе Н. Н. Ефимов